**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17 нче йорт. Тел.3-02-22. Факс 3-13-44

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-02-22. Факс 3-13-44

КАРАР
от 26.10.2018

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ ПР-268

Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты 2017нче елның 12нче сентябреннән ПР-153нче карарына үзгәрешләр кертү турында
“Татарстан республикасы Актаныш муниципаль районында инвалидларны яраклаштыру, аларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидлар өчен шартлар һәм мөмкинлекләр тудыру максатыннан инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында”

Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016нчы елның 9нчы июлендәге 649нчы номерлы карары “Инвалидларны яраклаштыру, аларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидлар өчен шартлар һәм мөмкинлекләр тудыру максатыннан инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында”, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016нчы елның 20нче декабрендәге 958нче номерлы карары “Татарстан Республикасы Дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына керүче торак урыннарына карата инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын җайлаштыру чараларын координацияләү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органын билгеләү турында” нигезендә Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты

**карар бирә**:

1. Инвалидларны яраклаштыру, аларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидлар өчен шартлар һәм мөмкинлекләр тудыру максатыннан инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия составына, кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017нче елның 12нче сентябрендәге ПР-153нче номерлы карарының 2нче кушымтасына, 3.16 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«3.16. Чараларны чаралар планына кертү турында карар кабул итү өчен нигезләмәнең 3.13 пунктында каралган бәяләмә чыгарылган көннән соң 10 көн эчендә инвалидның торак урыны урнашкан урын буенча муниципаль комиссия тарафыннан муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.»

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының “Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты 2017нче елның 12нче сентябреннән ПР-153нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында “Татарстан республикасы Актаныш муниципаль районында инвалидларны яраклаштыру, аларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидлар өчен шартлар һәм мөмкинлекләр тудыру максатыннан инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында” 2018нче елның 22 мартындагы ПР-50нче номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче
Башкарма комитет җитәкчесе И.Ш. Бариев

Исп. Ф.И. Яппаров
8 (85552) 3-44-30